16+ Тәкъдирләргә үпкә белдермәгез, үткәннәрдә язып күтелгән...
Фәнис МОТЫЙГУЛЛИН

# И, Язмыш...

Ноябрь, 2023 ел, №11

ГАЗЕТАДА ТОРМЫШТА БУЛГАН ХӘЛЛӘР ГЕНӘ БӘЯН ИТЕЛӘ



ФОТО: FREEPIK.COM

Вакыт дәва бирми.... Үзебез дә ел фасыллары төсле, көнгә чыккач әллә ничәгә төрләнсәк тә, яуган карлар эреп, җир ничек калган булса шулай ачылып, бар да күренгән кебек гомер итәбез. Әмма безнеке күренми... Киткәннәрне сагынып, исәннәре өчен борчылып яшибез. Теләкләр телибез, Аллаһтан сорап догалар кылабыз. Кызганычка каршы, безнең кебекләр арта тора. Кем генә булмасын, ул кемнеңдер кадерлесе, газизе. Ни өчен? Кая сулышы тукталса да, күңелләр ышанмый. Һаман үйлый, көтә... Көтүләре дә, билгесезлек тә бик яман.

## ҖИР ЯРАЛАРЫ АК КАРГА ТӨРЕНӘ

8-9 нчы битләр.

Һәрбер бәйрәм шатлыклы вакыйгадан башланып китми. 17 ноябрьдә билгеләнүче Халыкара студентлар көнен дә шатлыклы, күңелле Татьяна көне белән бутарга кирәкми. Әлеге дата Икенче Бөтендөнья сугышы чорының канлы вакыйгаларының берсе белән бәйле.

Тарихка кыскача гына сәяхәт: 1939 елда оккупациядә калган Чехословакия студентлары һәм укытучылары үз дәүләтләре төзелү көне уңаеннан (28 октябрь) демонстрациягә чыга. Солдатлар аларны куып тарата, бер студент яралана (соңрак җан тәслим кыла). Ян Оплетал исемле әлеге студентны җирләү баш күтәрү акциясенә әверелә, ул канлы террор

## Студент булу кирәкме?

Ахыры 2 нче биттә.

podpiska.pochta.ru

# Канатларым киселде

**Мин тормышта күп әйберләргә каршы чыксам да, әниемнең сүзләрен аяк астына салып таптаудан, аның рәнҗешеннән бик курыктым. Шуның аркасында шактый гына Лаеш шулпасы ашарга туры килде. Әле дә төгәл җавап бирә алмыйм: дөрес эшләдемме, юкмы? Тик башка әти-әниләргә бер үтенечем бар: балагызның язмышын үзегезчә хәл итәргә тырышмасагыз иде. Таякны артык каты бөксәң, ул сынарга да мөмкин...**




Кечкенә чактан кем булачагымны авыл халкы да чамалый иде. Дөресрәге, фаразлый иде. Мине урамда күргәндә: «Син шунда укырга керәсеңдер инде?» - дип кызыксыналар иде. Әмма әнием мине ул юлдан китмәскә үгетләде. Аннары – кулда аттестат һәм көмеш медаль, имтиханнарның яхшы нәтиҗәләре, ә күңелдә бушлык... Ахырга кадәр кая укырга керәчәгемне белмәдем. Китапчыктан бер уку йортының адресын сайлап алдым да, автобуска утырып, шунда киттем. Керүчеләр исемлегендә минем фамилия өченче иде. Миннән алдарак – ике ятимә кыз.

Тормыш сукмагым бөтенләй башка якка кереп китсә дә, кызыл диплом иясе булдым. Тик күңелем канатлары киселгән кош хәлендә иде. Укыганда ук эшли башладым. Ике көн төн уртасына кадәр эшлим, ике көн укыйм. Калдырган дәресләрне төркемдәшләремнән күчереп алам да, такта янына чыгып сөйлим (бездә шулай каты укытылар).

Аннары яратмаган башка эш урыннары. Кайда гына эшләсәм дә, китәргә гариза язгач, мине калырга үгетләделәр. Әйе, мин эшемне һәрчак җиренә җиткереп, намус белән башкардым, ләкин гомерем заяга узуын тоя идем.

Хыялымдагы юлга кайтыр өчен миңа дистә елдан артык вакыт кирәк булды. Хәзер үземне бәхетле һәм канатлы итеп хис итәм.

Казанда белем алганда уку юнәлешен үзгәртергә теләгән идем: театр училищесына дип тәвәккәлләдем. Әйе, бу төп хыялым булмаса да, күңелемә ятышлы өлкә. Инде әзерлек курсларына йөри башлагач, әни тагын каршы чыкты: янәсе, минем өчен борчылып, ул чирли башлаган, йөрәге авырта. Кемнең газиз кешесен вакытсыз гүргә кертәсе килсен инде? Әни хакына аны да ташладым.

Хәзер минем яраткан эшемдә булуымны күреп, әни дә сөенә, ә элек миңа каршы төшкәне өчен үкенә дә торгандыр бәлки?

Әле беркөнне яңа танышкан ана кешенең сүзләренә шаккаттым. «Кызыма егете тәкъдим ясаган. Кызга 19 гына яшь әле. Бер елсыз да өйләнешмисез, дидем. Бәлки аңарчы аралары бозылып та куяр. Яратам, ди. Мәхәббәт нәрсә бирә инде ул? Байны эзлә. Иреңнең 20 мең хезмәт хакы белән бүгенге заманда нишләмәкче буласың, дидем», – дип сөйләде ул ана.

Яраткан кешең белән әзне дә бәрәкәтле итеп тотарга, бергә-бергә байлыкны арттырырга була, югыйсә. Ә сөймәгән кешең синең алдыңа алтын таулары өеп куйса да, ул бары тик чүп өеме генә булып күренергә мөмкин. Бу – минем фикер. Башкалар бәлки моның белән килешмәс тә.

Хәзер мин үзем дә гаиләле, ана кеше. Үз-үземә сүз бирдем: балаларым үзләре теләгән һөнәрләрен сайлаячак һәм сөйгән ярлары белән гаилә корачак. Бәхетле булырга һәркемнең дә хакы бар бит.

**Асия НӘБИУЛЛИНА,**
**Казан.**

podpiska.pochta.ru

*Бар дөньяны афәт, сугыш чорнап алса да, аналар барыбер яшәү турында уйларга мәҗбүр.*

хикәя

Айсылу ИМАМИЕВА



# ТӨПЧЕК

Тормышның асты-өскә килгәндә, язмыш җилләре туп-туры битеңә бәргәндә ялгызың гына калып алга атлавы ай-һай кыен икән. Бүген ул моны тулысынча аңлады.

Кырның уртасын узганнан соң йөрәк ярсуын басар өчен җиргә утырды. Ямьсез булып кояш байый. Әйтерсең, җәннәт яктысы югалып, җәһәннәм уты җиһанны колачлап бара. «Уф», дип, маңгаена чыккан бөрчек-бөрчек салкын тир бөртекләрен сөртте хатын. Хәлсез иде ул. Соңгы көчләре сабые белән бергә аның арык тәненнән аерылган иде...

Күз ахыры якынлашып килә. Кыр буш, ә күңеле уй-кайгы белән тулы. «Нишләдем соң мин? Йә, нәрсә булды бу?! Дүртесе арасына бишенчесе сыймас идемени?» Юк, юк... Китсен ул. Аны бу караңгы дөньяда нәрсә көтә? Кешеләр бер-берсен юк итәр, үтерер, җир, мал бүлешер өчен генә туалар монда. Ил белән ил сугыша. Арыслангдай ирләр әниләрен бәхетсез, хатыннарын ялгыз, балаларын үксез итеп, сугышның комсыз авызында эреп юкка чыгып баралар. Бу яшәү түгел, хәтта куркыныч төштән дә хәтәррәк бер халәт. Нәрсәгә кирәк соң аның газизенә мондый куркыныч дөнья?! Әнисе аңа авырлык теләми. Шулай хәерлерәк... Әйе... Хатын бу мизгелдә үзен көзгедән күрсә, танымас иде. Күзләрендә чиксез әрнү, яшәештән бизү һәм әйтеп бетермәслек гаҗизлек. Ник кенә үзе дә аның белән калмады соң әле? Никме? Булдыра алмады, өйдә – иренең учагы бар, дүрт почмакта – дүрт балалары...

Алар алданрак туып өлгергеләр. Әтиле көннәре бәхет, матурлык, илаһи бер моң эчендә үткән икән. Өстәл өсте сый-нигъмәттән сыгылып тормаса да, тамаклары һәрвакыт тук, өсләрендә чиста кием, ә кичләр үзенә тартып тора. Хәтта кояш та һәрвакыт матур итеп байый. Кич саен әтиләре кулына тальян гармун алып, аларга үзе яраткан иң матур көйләрне уйный, йөрәкләре яшәү дәрте белән тула иде. Хәзер бары да артта, алда ни көтә – кем белгән. Инде аның ире юк. Кара тамгалы хәбәрне алуга аңлады – алар сугышта җиңелделәр. Аларның гаиләсе сугышта җиңүче була алмады...

Бәлки килер шундый көн, ул яшәгән ил сугышта җиңәр, исәпсез җан кыю, елгалап аккан кан, күз яшьләре исәбенә килер ул җиңү. Ә бәлки... Монысын уйласа, аңын җуяр кебек тоелды. Әле менә бу каһәр суккан кәгазь килмәсә, бишенче нарасыен да өенә алып кайтасы иде ул. Башта кара кәгазь килде, аннары, куркынган коштай, йөрәге тупырсый башлады, аннары тупырсау түбәнгәрәк төште. Ирен югалту авырлыгы белән тулгак авыртуы бергә кушылды... Йә Алла, хәзер өенә кайтып җитәр дә, барысы да начар төш кебек оны-тылыр. Аяклары гына атласын.

Өенә кайтып кергәндә игезәк малайлары һәм кечкенә кызы йоклап киткәннәр, ашыйсылары килүдән озак елаганнар ахрысы, күз төпләре күпереп тора, ә олы кызы мич кырыенда иске оекбашларга ямау салып утыра иде. Йөзе суырылган, чәчләре тузгып яулык астыннан чыккан әнисен мондый хәлдә күргән кыз бер мәлгә телсез калды. «Әни, син... Ничек? Кайда? Ә бала?» Баласын калдырганнан бирле йөзендә кан әсәре калмаган хатын кинәт кызара башлап җавап бирде: «Кызым, мин аны кырда калдырдым. Бар саны сау-сәламәт туды, тик ул интекмәсен кызым... Кыз-зым, әтиең үлгән...» Өзек-өзек чыккан сүзләрдән ике куркыныч хәбәр ишетеп, яшүсмер кызның акылы томаланды. Кулындагы оекбашы идәнгә төшеп китте. «Әни, ни сөйлисең? Әни, алдама. Әле иртән генә барысы да әйбәт иде. Ни өчен? Нигә?» Кызының шулай үрсәләнеп елавыннан хатынның йөрәгендәге әрнү һәм гаҗизлек артканнан артты гына. «Мин нишләдем – белмим», - диде ул баласын күкрәгенә кысып. Алар кочаклашып, тилергән кешеләрдәй илереп елый башладылар. Тик хатынның күңелендәге әрнеш яшь тамчыларына кушылып акмады, киресенчә, күңел түренә үрмәләп, җанны пәрә-пәрә телгәләргә тотынды. Йокыга киткән нарасыйлар көйсезләнеп куйгач, хатын, кызын кулыннан тартып, урамга алып чыгып китте. Тышта дөм караңгы, әйтерсең күк юкка чыккан. «Калдырдым мин аны, кызым, беләсеңме? Кырда берүзен әрекмән яфрагына төрдем дә, шунда куеп калдырдым. Йә Алла, мине кичермә! Нишләдем соң мин?» Калтыранган куллары бишмәтенең төймәләрен бер төймәләде, бер чиште.

podpiska.pochta.ru

# «БАЛА ТАПТЫМ, ЛӘКИН БАКМАДЫМ...»

**Күзләр - күңел көзгесе диләр. Ул апаның карашы шулхәтле моңсу, әрнү-газаплары йөзенә чыккан иде, каршыма килеп утырды да, күңелен бушата башлады.**


ФОТО: FREEPIK.COM

Әчем тулы ут минем. Иремнән дә уңмадым, балалардан да бәхетем юк. Картайган көнендә үз фатирында куркып яшә инде. Күңел тынычлыгым югалды, үземә урын таба алмыйм. Төннәрен куркып өйдән йөгереп чыгып киткән чакларым әз түгел. Күптән түгел генә минә тагын, ирем эчеп кайткач, таң беленер-беленмәс, эчке күлмәктән, яланаяк чыгып качтым. Яшь вакытта гомерләр ничек тә уза, ә менә картлык көнендә тынычсызлыкта яшәүләре бигрәк яман икән...

Тормыш иптәшем Сабир белән бер-беребезне яратышып өйләнештек. Безгә сокланмаган кеше булмагандыр ул: бәхет тулы касәбез беркайчан да чайпалмас, гаиләбез таркалмас шикелле иде. Бер-бер артлы ике малай һәм кыз таптым. Тик аларны тиешенчә тәрбияли генә алмадык. Гаиләне туендырам дип, көнне төнгә ялгап эшләдем дә, эшләдем. Ана назы, гаилә җылысы җитеп бетмәде балакайларыма. Тик моны мин соң аңладым.

Ни чәчсәң, шуны урырсың, диләр. Тәүфыйксыз бала – тәмугъ газабыдыр инде ул. Балаларымны табуын таптым, тик бакмадым, аларны күпчелек урам тәрбияләде. Юньсез дусларны юлдаш итеп, ничек кыек юлга басканнарын сизми дә калдым. Бу хакта белеп алгач, аларны акылга утыртырга тырышсам да, соң иде инде. Ахыр чиктә хәерсез эшләре өчен ике улым да төрмәгә эләкте. Хәзер аларның кайдалыгын да белмим. Олысы иреккә чыккач бер балалы хатынга кергән һәм күптән түгел генә кызы туган дип ишеттем. Оныгымны барып күрү бәхетенә дә ирешә алмыйм бит. Уртанчысы да каядыр билгесезлеккә китеп югалды. Бу хәтле әрнү-газапларга йөрәгем күпме түзәр?

Кызым белән дә, ичмасам, рәхәтләнеп сөйләшә алмыйм. Хәер, беркайчан да бер-беребезне аңламадык, шулай җиде ят булып гомер итәбез. Яшермим, Гөлүсәм балачактан бик тәртипсез тотты үзен: укымады, олыларны тыңларга теләмәде. Мәктәп эскәмиясеннән үк бер ир кочагыннан икенчесенә сикерде. Мин юкта аларны өйгә дә алып кайта иде. Юньсез баламның сүзе бер булды: «Миндә эшең булмасын, ничек телим – шулай яшим!» - дип кенә кычкыра иде.

Ни дисәң дә, теләп тапкан балаларым, бәгырь кисәкләрем алар. Кызымны кеше итү өчен кулымнан килгәннең барысын да эшләдем, югыйсә. Аңа хәтта аттестатны да сатып алырга туры килде, документсыз бернинди уку йортына алмыйлар бит. Көч-хәл белән, акча төртә-төртә, училищега да керттем, тулай торактан да урын булдырдым. Тырыша-тырмаша торгач, кызым аш пешерүче һөнәрен үзләштерде. Хәзер акчалы урында, ашханәдә эшли. Өсте дә бөтен, тормышы да мул, тик балалары гына юк, таба алмый. Шулай булуы, бәлки, яхшырактыр да әле... Дус кызының баласын ташлап китүенә дә һаман йөрәгем сыкрый. Акылыңа кил, дип күпме үгетләдем аны. Тыңламады, нарасыена әйләнеп тә карамады.

Кичә Гөлүсәмнең фатиры төбендә озак басып тордым. Галина булган хәзер, хәтта мин кушкан исемнән дә баш тарткан. Газиз әнкәсе белән сөйләшергә теләмәде, күпме шакысам да, ишекне ачмады. Атасы да балаларны күрергә теләми, алар минем өчен бөтенләй юк, ди. Иремә бер ышаныч калмады. Хастаханәдән кайткач, әллә нинди сәер хатыннар килеп, фатирга хуҗа булмакчы булып йөрде. Кеше ышанмаса да, әйтим инде, олак фатирдан, ирең белән мин торачакмын, дип янадылар үземә. Өеңнән дә куып чыгарсалар, нишләрсең? Аллаһы Тәгалә үзе сакласын.

Гомер буе ашханәдә аш пешерүче булып эшләдем. Гел аяк өстендә булып, авыр капчыклар ташып, шунда бөтен сәламәтлегемне югалттым да инде мин. Хастаханәдә дәваланып, аяк буыннарын алыштырдым, көч-хәл белән генә, таякка таянып кына, үз-үземне йөртәм. Табиб миннән: «Аякларыгыз тимер, сез хәзер робот сыман», - дип көлә. Тик җан тимер түгел шул, сызлый. И, кызым, зинһар, гаепләмә мине. Язмышым сезгә сабак булсын, балаларыгызга вакытны, игътибарыгызны җәлләмәгез. Балакаем, гомер тиз уза ул. Ана җылысын тоеп үссен алар.

**Зилә МӨДӘРРИСОВА**
**язып алды.**

podpiska.pochta.ru




ФОТО: UNSPLASH.COM

# Әллә... җен булган?

Ак белән кара, яхшылык белән явызлык бертигез булмаса, баланс югалып, Җир йөзендә тереклек бетә, ди. Җен дигәннәре дә бардыр ул. Маңгайга-маңгай килеп бәрелмәсәм дә, үзем күрә яздым. Ап-аек, акылым камил иде, ул хәлдән соң да, шөкер, түбәм бер якка авышмады.

Хәл болайрак булды. Студент чак, ялга кайткан вакыт иде. Көз көне, тымызык кына яңгыр сибәләп тора. Урамда йөрисе килмәсә дә, клубка чыгып кермичә дә булмый. Яшь чак бит. Клубта бераз булгач, кайтырга чыктык. Яхшы сыер гына туп-туры өенә кайта, ә без яхшы сыер түгел, дус егет белән урам әйләнеп килергә булдык. Кайчагында кунак кызлары кайтып, аяк киемнәрен пычратмас өчен, клубка чыкмыйча капка төбендә генә утыргалыйлар иде.

Аякка ябышкан балчыкны селки-селки сөйләшеп атлыйбыз, тымызык кына сибәләп торган көзге яңгыр гына бераз эчне пошыра. Без яшь чакта шундый көннәрдә бакчадагы куышка, мунчага, келәткә кереп утыру гадәти хәл иде. Авылда подъездлар юк бит, кая барырга? Юл уңаеннан гына без дә бер мунчага кереп утырдык. Яшь чак бит, юләр чак.

Тыныч кына гәп корып утырабыз шулай, бер мәлне урам яктан аяк тавышлары ишетелде. Мунча янәшәсендә генә үскән талның җиргә сынып төшкән ботак-сатаклары өстеннән тавыш-тынсыз гына йөреп булмый. Кем булыр бу, туп-туры мунчага таба килә бит! Ышыкланыр урын эзләүче берәр парлыдыр инде. Капка төбендә басып торып өши башлаганнардыр. Парлылар да түгел, ахры, бер кешенең генә аяк тавышы ишетелә. Ярый, килсен, ярамаган эш эшләп утырмыйбыз. Шомландыра гына бераз. Мунча түбәсенә тал ботакларыннан шыбырдашып коелган тамчылар да шомны өсти генә бара. Мунчаның эченә үк кермәгән идек бит, коридорында гына утырабыз. Урамдагы һәрбер тавыш ачык ишетелә.

Килеп җитте теге. Кергәч беләбез моның кем икәнен, дип утырабыз шулай, шулчак мәче кебек ишекне тырный башлады бу. Эчтән бикләмәгән, юка тактадан эшләнгән ишекне әллә чынлап та мәче тырный микән, кеше болай тырный алмый. Сәер, яңгыр яуганда мәчеләрнең урамда йөргәнен күргән юк, ул безнең кебек тиле түгел. Чыгып карыйсы да килми. Баягы дөп-дөп итеп ишетелгән аяк тавышларына караганда, кечкенә җан иясенә охшамаган бу. Шундый вакытта кеше үз-үзен куркытып, әллә ниләр уйлап бетерә икән. Кара көзнең яңгырлы төнендә, дөм-караңгы мунча эчендә, җитмәсә тышкы якта кемдер ишекне тырнаганда ул уйларның бигрәк тә әллә ниндиләре килә башка. Бу сәер хәлгә аптырап утырабыз, теге нәрсә мунчаның түбәсенә менеп китте. Түбәгә «дөп-дөп» итеп баса. Яңгырда юешләнеп, ялтырап торган рубероид өстеннән кеше йөри ала торган түгел. Акылы булган кеше нишләп анда менсен? Ике-өч адым ясады да бу (кыекка менеп җитте ахры), бераз икенче якка таба шуып төште, аннан соң «дөп» итеп җиргә сикерде. Башка берни дә ишетелмәде.

Елтыр-елтыр карашып, булып узган хәлне ми күзәнәкләре аша уздырып бераз утырганнан соң, чыгарга булдык. Ишекне төртәбез – ачылмый. Яшь чак бит, курку да юк түгел, тибеп ачтык. Ишек бигенә тал чыбыгы тыгылган булып чыкты. Түбәдә бернинди эз күренми, пычрак аяк киеменнән эз калмый булмас иде. Яңгыр юып төшерерлек ара да узмады. Бөтен белгәннәрне укып, мунчаның артына чыктык. Мунчага терәлеп диярлек куаклар үсә. Бу чытырманга сикереп төшкәч чыбык-чабык сынганы, кыштырдаган тавышлар ишетелер иде (мондый нәтиҗәләргә соңыннан, йөрәкләр бераз нормаль тибеш алгач кына киленде). Әлеге чытырман бакчаның арткы коймасына хәтле бара, койманың теге ягында елга. Биредә басма да юк, су эчендәге машина тәгәрмәчләренә басып яңгыр яуганда түгел, аяз көнне дә чыгулары җайсыз. Бакча эчендәге чытырманга кереп карарга шикләндерде һәм тайдык без моннан.

Бу хәлгә кем ышанды, кем юк, кирәкмәгән җирдә йөрмәскә генә диючеләр дә булды. Ә бер абзый болай диде: «Ул елга буенда шуның ише сәер хәлләр элек тә, әле без бала чакта да булгалаганы бар. Мунча җенле түгел, урыны шундый аның». Утыз елга якын вакыт узса да, авылга кайткач шул тирәдән үткәндә әлеге сәер хәл келт итеп искә килә дә төшә. Хәзер мунча да юк инде анда, чытырманны чистарткач бакча да матураеп калган. Әмма теге «кыштыр-кыштыр» ишек тырнаган, түбәдә йөргән аяк тавышлары искә төшеп, күңелгә барыбер шом салып куя. Хәзер мине анда дус егет түгел, бер кашык су белән чайкатып эчәрлек сылу кыз белән дә илтеп утырта алмыйсың. Аяк киемен пычратмый торган теге кунак кызы чакырса да бармыйм.

**Фәнис МОТЫЙГУЛЛИН.**

podpiska.pochta.ru

ҮЗӘКЛӘР ӨЗЕЛГӘНДӘ...




# Хоккейчы Ринат бәете

**БӘЕТКӘ АҢЛАТМА**

***Ринат Фәнис улы Мотыйгуллин. 27.06.2000 – 13.05.2019.***

Хоккейга 9 яшендә генә килә. Беренче тренеры аңа: «Вундеркинд булсаң, әле бу яшьтә башлап та нәрсәгәдер ирешергә була» - ди. Ринат вундеркинд булмый, әмма үҗәтлек, тырышлык, ихтыяр көче аңарда хәттин ашкан була. Лениногорск, Әлмәт, Казан командаларында уйный. Төрле елларда куплләгән турнирларда (шул исәптән халыкара), Казан, Татарстан, Россия беренчелегендә чыгыш ясап, җиңүләр яулый. Ике тапкыр Россия беренчелегендә (ПФО) җиңеп беренче өлкән разрядка ия була. Берничә тапкыр иң нәтиҗәле сакчы булып табыла, «Җиңүгә ихтыяр һәм омтылыш» титулы иясе.



Урта мәктәпне тәмамлагач Казан энергоуниверситетына укырга керә. Хоккей белән шөгыльләнүен дәвам итә. Шул ук елда хоккейчы карьерасын Россия яшьләр лигасында (МХЛ) дәвам итү, шулай ук Кара диңгез флотының «Черноморец» командасында уйнау мөмкинлеге була, бу клуб белән элемтәләр урнаша. Ләкин осталыгын арттыру өчен Европа хоккей мәктәбен узарга ниятли – Словакияның «СХК 37 Пьештяны» клубыннан чакыру ала. Документлар әзерләү озаккарак сузылу аркасында бу эшне киләсе елга кичектерергә туры килә.

Ринат өйрәнүләрен дәвам итә, 2019 нчы елда МХЛ, Европа, Казахстанның берничә хоккей клубы белән сөйләшүләр алып барыла. Май азагында Словакиядан кабат чакыру килеп ирешә, ә бу вакытта исә Ринатның бакыйлыкка күчкәненә бер атна була инде...

Урта сыйныфларда укыганда Ринат матур әдәбият уку белән мавыгып китә, күпчелек чит ил классикларына өстенлек бирә. Шул чорда рус телендә шигырьләр, соңрак хикәяләр яза башлый. Аның инглиз телле журналист, тәрҗемәчелек итү хыялы да була, әмма техник профильне сайлый. Иҗат итүен туктатмый, шигырь-хикәяләр, иншалар, миниатюралар, көндәлекләр яза (язмаларның күбесе белән үзеннән соң гына танышырга мөмкин булды).

...Бер көн кала Ринат соңга хәтле киләчәккә уй-планнары турында сөйли. Берничә хоккей клубы белән сөйләшүләр бара, хоккей агентлары яңа вариантлар тәкъдим итә. Җәйге җыеннарга (сборларга) хәтле аның әле имтиханнар тапшырасы, машина йөртү таныклыгын да алып өлгерәсе бар. Хоккей темасыннан китеп, Ринат киләсе елга БДИ (ЕГЭ)ны яңадан бирәм дип сөйли, башка һөнәрне үзләштермәкче. Шундый хыял-планнары белән бүлешеп утырган Ринат, бер тәүлек тә үтми, бакыйлыкка күчә... Икенче көнне тренажерлар залында күнегүләр ясаганнан соң яшь хоккейчының йөрәге тибүдән туктый...

podpiska.pochta.ru

Бәет язам. Нидән генә, ничек итеп тотыныйм?
Фәнис улы Ринат хәлен ничек кенә тасвирлыйм?
Ярар иде, яшен яшәп, олысына кагылса.
Тик жәлләми үлем җиле, исә чәчәк атканда...
Кеше күңеле шуңа әрни, әти-әнинең бигрәк тә.
Унтугызы тулар-тулмас вафат булды Ринат та.
Күнегүләр ясагачтан, душта юынды Ринат.
Шунда гына ял итәргә җайлы тора караваt.
Бераз хәл алыйм дип ятты, ләкин шуннан тормады.
Мәңгелеккә йомды күзен, яшь йөрәге туктады.
Тыеп булмый күз яшьләрен, аянычлы үлемнәр...
Хуш, бәхил бул, улым,
башка сүзләр килми хәлемнән.
Әби-бабай һәрвакытта «Онык!» диеп куанды.
Акбүренең туфрагыннан көчне әти дә алды.
Вакыт җиткәч әтием дә, юлын сайлап шәһәргә,
Яшьли киткән дөнья куып, укырга да яшәргә.
Хоккей җене кагылгач та, күчтек бергә Казанга.
Җан-тән белән уйнагачтан, кабул итте команда.
Баштан «Дулкын» клубында,
«Ак Барс»ка тартылдым.
Өмет зурдан – киләчәгем бергәләшеп уйланды.
Алмагачлар шау чәчәктә, һавасы чиста, хушлы.
Шундый матур май көнендә уйнады үлем кулы.
Алып китте мәңгелеккә Фәнис улы Ринатны.
Ышанмыйча бар халык та уртаклашты кайгыны.
Чибәр иде, төз гәүдәле, хоккейчы булды Ринат.
Укырга да керде әле, әй, әти-әнисе шат!
Әтисе дә, кош тоткандай, гел очып кына йөрде.
«Шәһри Казан»да эшли ул, мәшәкатькә күмелде.
Коллектив та бик сөенде улының уңышына.
Теләктәшлек белдерделәр Ринатның булмышына.
Әти-әниләрен һәркөн уңышлар сөендерде.
Спорттагы тырышлыгы, бар чыгышы күренде.
Малай туып, шундый үссен – әтисенә охшардай.
Ямьле холык, ихлас, сабыр, эшчән, таза, батырдай.
Кояш кебек гел елмаеп, куанып яши Ринат.
Бар да уңышлы башланды.
Шатланды Фәнис кабат.
Ни кызганыч, уңыш белән кайгы килә гаиләгә.
Сабыен югалтканнарга ни кала соң бу җирдә?..
Киләбез дә бу дөньяга, гамьсез генә яшибез.
Тәкъдиребез туганчы ук язылганын белмибез.
Төрле хәлләр үлем белән тәмамлана кешегә.
Якты эшләр калса иде күчкәндә ул мәңгегә.
Ринат та бит – якты йолдыз,
атылып сүнде кинәттән.
Оҗмах тели әти-әни бары ихлас йөрәктән.
Тыныч йокла, Ринат улым, онык – әби-бабайга.
Дога кылсак барыбыз да, җиңел булыр балага.
Сөлек кебек гүрдә ята Акбүренең баласы.
Тәкъдир шундый –
һәммәбезгә кайчандыр бер барасы.
Ләкин иртә, бик тә иртә килде үлем Ринатка.
Бөреләнгән чәчәк кебек илтеп куйдык зиратка.
Сабыр булыйк. Сабырларны Аллаһым бик ярата.
Шөкер итсәк, зекер итсәк, меңе белән кайтара.

**Мидхәт ГАЗЫЙМОВ,**
**Зирекле авылы, Яңа Чишмә районы.**

**АВТОР ТУРЫНДА**



Мидхәт Гариф улы Газыймов – Яңа Чишмә районының Зирекле авылында гомер кичереп, мөгаллимлек иткән, утыз елга якын туган авылының төбәк музеен җитәкләгән, берничә дистә китап язган, авыл музеен республика дәрәҗәсенә күтәргән шәхес. Мидхәт ага Зирекле авылы тарихы, аннан чыккан күренекле шәхесләр, имамнар, һөнәрчеләр, сугыш корбаннары һәм ветераннар, шул төбәкнең халык авыз иҗаты, бәетләре, мөнәҗәтләре, географик атамалары, гореф-гадәтләре турында китаплар язды. Үзе дә бәетләр иҗат итте, аның тырышлыгы һәм ярдәме белән шул төбәк авторларының күмәк җыентыклары, аерым китаплары дөнья күрде. Ел башында сигез дистәсен тутырган Мидхәт Гариф улы Газыймов октябрь аенда бакыйлыкка күчте. Ул чын мәгънәсендә туган төбәгенең патриоты, татар милләте өчен зур эшләр башкарган олы шәхес иде.

**Ринат МОТЫЙГУЛЛИН**
**шигырьләре***

***

Сез хокуклы бәя билгеләргә
Күпмәгънәле шигъри юлларга.
Изге түгел, еш та гөнаһ кылмыйм,
Серле байрак түгел кулларда.
Бу юлларда күпме эзләсәң дә
Ачылышка юктыр табылу.
Ә тормыш бит – уен,
минем өчен
Чынбарлык ул бары мавыгу.

***

Аш(ы)гып кабул иткән карарларның
Төшенергә авыр серенә.
Син утрауда яшим диеп калдың,
Кораб киткәч диңгез төбенә.
Тормыш итеп була бу утрауда,
Ярый белсәң әгәр җирлегә.
Робинзонлык – кәттәлек тә үзе,
Шуннан гайре юктыр берни дә.
Синең юлың – кыргый океанда,
Яңгырларның җый да суларын,
Компассыз да табу насыйп булыр
Ымсандырган хыял ярларын.

2018 ел.

** (Шигырьләр русчадан тәрҗемә ителде).*

podpiska.pochta.ru

*Сандугачлар үсеп җиткәч*
*Сайрар талларын кисәләр,*
*Ышанмас идем, үләсең*
*Унтугыз яшьтә, дисәләр...*
*Сыерчыклар кызыл сөйми,*
*Кызыл оялар элмәдем.*
*Сыерчык бала чыгаргач*
*Үләсемне мин белмәдем.*

# Мин тормышны яраттым!

***Ринат Мотыйгуллинның***
***якты истәлегенә багышлана***

Бәхетле һәм ваемсыз бер
Бала булып үсеп җиттем.
Спорт юлын сайлап алып
Туган йорттан чыгып киттем.

Әткәй белән юлга чыктык,
Калды әни, сеңлем, туган як.
Аз булдымы өчегезне
Бергә кочасым килгән чак!?

Тиң яраттым, тигез сөйдем,
Сезгә карап туялмадым.
Кичерегез, улыгыз булып
Сезгә хезмәт куялмадым.

Җир җимертер яшькә җиткәч,
Мәңгелеккә йомдым күзем.
Хушлашу авыр булгандыр,
Раббым бирсен сезгә түзем.

Китеп бардым башка акыл,
Беләккә көч кергәч кенә.
Мәхәббәтнең ни икәнен,
Сөю тәмен белгәч кенә.

Шук та булдым, шаярдым да,
Юк-бардан да кызык таптым.
Мәңге яшәр кебек идем –
Мин тормышны бик яраттым!

Кем уйлаган, май аенда
Гөлне кырау сугыр диеп,
Яши башламаган гомрем
Шул гөл кебек сулыр диеп.

Әти белән киңәшләшеп
Эшли идек һәрбер эшне.
Ахир дуслар кебек сез, дип
Соклана иде һәр кеше.

Серләребез уртак иде,
Бергә өйдә, шугалакта.
(Мәңгелеккә калыр идем
Шул ваемсыз бала чакта).

Бер төнне без, бирелеп китеп,
Күпме хыял-план кордык.
Ул көнне без әти белән
Керфек какмый таң аттырдык.

Күп сөйләштек... минем хакта –
Нинди белем алачагым,
Һөнәрем ни, хатыным нинди,
Ничә балам булачагын.

Күбесенчә мин сөйләдем,
Әткәй дәшми тыңлап торды,
Торыр вакыт җиткәч кенә
Кисәтеп бер тамак кырды.

Өйдән бергә чыгып киттек-
Ул бер якка, мин бер якка.
Әткәйне кочасым килде
Кире кайтып нәкъ шул чакта...

Кем уйлаган шул алсу таң
Соңгы таңым булыр диеп,
Боз яраткан яшь йөрәгем
Салкын боздай сулыр диеп.

Тренировкалар беткәч,
Бер йотым су алып каптым.
Күкрәгемне нидер кысты,
Аулак урын табып яттым.

Бар да китте, япа-ялгыз,
Тын кысыла, чәнчи йөрәк.
Җан бугазда, тән калтырый,
Һава җитми, һава кирәк!

Сез тапканда җаным инде
Коштай күккә ашкан иде.
Хиссиятем, кичерешләр,
Тәнсез тормыш – башка инде.

Җансыз каткан тәнем тапкач
Ничек түздең икән, әткәй?
Ул көнне иртән йөрәгең
Сыкрап куймадымы, әнкәй?

Шикәр кебек ак тәнемне
Ак кәфенгә салдыгыз сез,
Салкын гүргә куйган чакта
Яшьсез-өнсез калдыгыз сез.

Мин салкыннан курыкмыймын –
Үстем бозда аунап-уйнап.
Сезнең җаннар өшидер лә
Һәр көн саен мине уйлап...

Киткәнгә инде үкенмим,
Бәрзаһ – һәркем үтәсе юл.
Хоккей уйнар идем тик бер,
Монда боз юк икән шул ул!...

Калды дуслар, калды кызлар,
Алары тик болай гына.
Чулпан сеңлемне сагынам,
Белә бары Ходай гына!

Сеңелкәем! Яшә җирдә
Бәхет эчеп, уйнап-көлеп.
Назланып, сөеп-сөелеп,
Бу тормышның кадерен белеп!

Әтиемнең исемнәрен
Тау-ташларга уяр идем,
Мин диеп яшәгән өчен
Һәйкәл ясап куяр идем.

Ринат диеп типте калебең,
Мин дип тордың, мин дип яттың,
Синең кебек әти бирсен
Барлык балаларга раббым!

Минем киемнәрне, әни,
Энекәшем киеп үссен.
Бар тормышың тыныч, матур,
Кайгы-хәсрәтләрсез үтсен.

Кем уйлаган яшь гомерем
Чәчәк кебек сулыр диеп,
Үземнән соң догачылар
Әби-бабам булыр диеп.

Сезнең дога безнең якка
Чишмә булып ага икән.
Җылы сүзләр каберләргә
Нурлар булып тама икән.

Сез бер дога кылган саен
Уч тутырып мин су алам.
Дога бетсә, чишмәм кибәр,
Шуны уйлап моңсуланам.

Сау булыгыз, якыннарым,
Килер таңнар имин тусын.
Безнең бергә очрашыр көн
Мөмкин кадәр ерак булсын!

**Илшат МИҢГӘРӘЕВ, Әлмәт.**

podpiska.pochta.ru

**Декабрьнең зыкы салкын иртәсендә төш күреп уянды Гаҗилә. Төшендә инде күп еллар элек вафат булган әнисе Хәдичәне күрде ул. Ап-ачык итеп, якыннан күрде. Әнисе күзне камаштырырлык ап-ак яулык бәйләгән, балаитәкләп теккән чәчәкле күлмәген кигән. Гөлләр үстерергә бик ярата иде ул. Менә хәзер дә Гаҗиләгә елмаеп карады да:**
**- Матур гөлемне алырга кайттым, - диде. Тәрәзә төбендә ал чәчәк атып утырган яран гөлен алды да, китеп тә барды Хәдичә...**



# Өзелгән җыр

Бу төш көне буе уеннан чыкмады Гаҗиләнең. Нәрсәгә юрарга да белмәде. Әнисенә атап күрше карчыгына сәдака да кертеп чыкты.

Көннәр бер-берсен алыштыра торгач, Яңа ел бәйрәме дә килеп җитте. Гаиләдә олы кыз Мәдинә бәйрәмгә әзерләнә. Кул эшләренә ифрат та оста Гаҗилә кызына марлядан Кар кызы күлмәге текте. Бик тә матур килеп чыкты күлмәк: ике рәт балаитәкле, кызының зифа буен тагын да зифаландырып җибәрә. Мәдинә күлмәкне киеп карады. Бигрәк килешле чыкты, нәкъ Кар кызы булды да куйды! Инде күлмәкне бизисе генә калды. Бизәү эшен Мәдинә үзе башкарды. Әнисенә охшап, кулы тегү-бәйләүгә ятып тора иде кызның. Гаҗилә кызына сөю аша сокланып карады: «Күзләрем генә тимәсен берүк! Бәхетең генә булсын, балам!» Бу сүзләрне яшүсмер кызына кычкырып әйтмәгәненә кат-кат үкенәчәген белми иде шул әле яшь ана.

Мәдинә бу бәйрәмне бигрәк ашкынып көтте. Бәйрәмдә җырлаячак җыры да күптән әзер. Инде менә күлмәк белән калфагына соңгы бизәкләрне тегә. Туктаусыз шаярды, көлде кыз. Әллә яшүсмерлек чоры булдымы, әллә язмышы ашыктырдымы – хәзер моны берәү дә әйтә алмый инде.

Мәдинәнең бәйрәмегә китүен әнисе күрми дә калды. Бәйрәмнән кайтып кергән кызны танырлык түгел иде. Баскан җирендә ут чыгарып торган кыз сүнеп, сүрелеп калган.

– Әни, мин бик нык туңдым...

Ул елны кыш аеруча салкын килде. Инде декабрь аеннан ук үз көчен күрсәтә башлады. Бәйрәмгә дип әзерләгән киемнәрен бозудан куркып, Мәдинә бик юка киенде. Житмәсә, бәйрәм узачак зал да салкынча иде. Әнисе кызны шелтәләп алды. Өйдәге иң җылы урынга – мич башына җылынырга менде кыз. Икенче көнне Мәдинәдә бик көчле температура иде. Бал белән мәтрушкәле чәйләр эчергәч төшкән кебек тә булды үзе. Ашкынып көткән каникулны урында уздырды кыз. Кайбер көннәрне хәле бераз әйбәтләнеп киткәндәй була. Әти-әнисе тырышып дару үләннәре белән дәвалый. Шулай гыйнвар ае да узып китте.

Февраль башында кызның кабат температурасы күтәрелде. Ә беркөнне тамак астында кыяр формасында шеш килеп чыкты. Әти-әнисе кызны участок хастаханәсенә алып китте. Ул вакытта ни юлы юк, ни техникасы, дигәндәй. Мең бәлалар белән барып җиттеләр. Мәдинәне баш табиб үзе карады. Тиешле тикшеренүләр үткәргәннән соң ахыргы диагнозны куйды һәм:

– Соңга калгансыз, - диде.

Аяз көнне яшен суккандай булды бу сүз. Кызларына көчле салкын гына тимәгән булып чыкты. Табиб «менингит» дигән куркыныч диагноз куйды.

...Ундүрт яше туларга нәкъ бер ай калган көнне китте Мәдинә. Ул төнне буран ярсый-ярсый ишек-тәрәзәгә какты, өй стенасына сарылып үксе-үксе елады. Өй эчендә кызы өчен өзгәләнгән Гаҗилә җанына урын таба алмады. Уттай янган кызын кочагына алды. Кызның тән кайнарлыгы аның тәнен, тәнен генә түгел, җанын пешерде. Бу вакытта Мәдинә беркемне дә танымый иде инде. Әле яшәргә дә өлгермәгән кыз баланың җаны Мәңгелеккә очты. Ак бураннарга уралып, әти-әнисен, туганнарын, аны бик тә якын күргән күрше апаларын калдырып очты. Салкын февраль буранында Мәдинәнең тормыш җыры өзелде...

**Динә ВИЛДАНОВА, Казан.**

# Улым саклый

Эштә ковидтан вакцинация ясатырга куштылар. Кичтән әйтеп яттым: әгәр дә улым төшемә керә икән – ясатмыйм, кермәсә – ясатам. Нәкъ шул төнне мин бүлмәдә утырам, ян ишек ачылып китте. Яп-якты, андый яктылыкны күргәнем дә юк. Кояштай балкып, ап-ак киемнән мәрхүм улым килеп керде. Тормыштагы кебек ачык, бар кеше белән елмаеп исәнләште дә, икенче ишектән кереп китте. Шулай итеп, мин вакцина ясатмадым. Инде октябрь аенда соңгы срок, эшкә кертмибез, дигәч, тагын шулай адарынып яттым. Тагын шул төнне төшкә керде балам. Тагын ясатмадым. Эштән дә кумадылар, Аллага шөкер.

Төшләрне еш күрәм. Кайвакытта куркып та куям төшләремнән. Иремә сөйлим дә, ник миңа керми соң алар, гел сиңа гына керә, ди. Улымның ел ашын үткәрәсе төнне, төшемдә иңбашымнан тотып: «Әни, мин сине гомер буе саклап барачакмын, мин янәшәдә», - диде. Сизәм мин улымның саклавын.

**Раушания НУРИЕВА, Казан.**

podpiska.pochta.ru

# Бакыйлыкта очрашу булачак


ФОТО: FREEPIK.COM

**Бер мәктәптә укыган, аннан соң бергә эшләгән дус малайның әти-әнисе бер-бер артлы бакыйлыкка китеп барды. Әнисе алданрак китте, аның җидесен уздырган көнне әтисе дә бакыйлыкка күчкән иде.**

Менә шушы апа берсендә минем төшемә керде. Ул кухняда нәрсәдер пешереп йөри, өстәл артында сары чәчле, кечкенә генә бер матур кыз утыра. «Апа, мин әйтәм, балалар кайткалыйлармы соң?» «Елдан артык инде күренгәннәре юк», - дип җавап бирде дустымның әнисе. Кыска гына төш шуның белән бетте дә.

Иртән уянгач, дус малайга шалтыратам. «Әниеңә дога кыласыңмы?» - дип сорыйм тегенәрдән. «Белгәннәремне укыйм да, кылам инде, ди. Ник?» - дип сорый бу. «Әниеңне төшемдә күрдем», - дим. «Ничек күрдең?» - дип кызыксынып сорагач, күргән төшемне сөйләп бирдем моңа. «Узган җәйдә каберенә кайта алмадым шул, елдан арта инде», - ди дус малай (әнисе дә бит төшемдә елдан артык күренгәннәре юк дигән иде). Әнисе янында кечкенә генә кызның да булуын әйткәч, дустым миңа бер кыз туганнары булуын, кендеге дөрес киселмәве аркасында, туугач ук үлүе хакында сөйләде. Бу хәлне авылда да берничә кеше генә хәтерли, күрәсең, чөнки алар Казанга күчеп киткәннәр иде. Туганнары арасында да белүче сирәк булган, әнисе бу хакта бөтен кешегә дә сөйләмәгән. Мин дә бу хәлне белми идем, төшемдә аның әнисе янында кечкенә кызны күргәч кенә белдем.

Бакыйлыкка күчкәннән соң без якыннарыбыз белән очрашачакбыз, ул гына да түгел, алар безне анда каршы алачак. Бу хакта күп язылган, якыннары бакыйлыкка күчкән чакта аларның янында булучылар сөйләгәннәрне тыңласаң, исләр китәрлек һәм алар безгә бик күп нәрсәне аңлатып бирә (аңларга теләгәннәргә һәм моны әкият дип кабул итмәүчеләргә). Мин күргән төш тә шуның бер мисалы, дустым сөйләгән хәл бик күптән булган, һәм, алда әйткәнемчә, ул хакта бик аз кеше генә белгән. Ә әнисе ни өчендер минем аша улының аның каберенә зыярәт кылмавын искәртте. Белгечләр төштә бакыйлыкка күчкән якыннарыңны күрүне безнең алар белән булган мөнәсәбәтләрнең дәвам итүе, элемтәләрнең, хисләрнең өзелмәве белән аңлаталар.

**Илназ КАМИЛОВ.**

# ТӨШЛЕК

**Ата-ана.** Ата һәм ананы төштә күрү рәхәтлек һәм мәгърифәтле тормышка ирешү белән юралына, барча кешеләрнең хөрмәте һәм шәфкате шушы төшне күрүчегә ирешер.

Атабыз Адәм пәйгамбәрне төштә күрсәк, дәрәҗәдә олылык һәм халыкны үзебезгә буйсындыруга булыр.

**Ау, аучы.** Төшкә аучы керсә, зыян ирештерүче булыр. Әмма мылтык атучыны күрсәң, яхшы хәбәр ирешүгә юрарга киңәш итә.

Төшеңдә үзең аучы булып, киек ауласаң һәм тотсаң, саф кыз алырсың.

**Ахмаклану.** Төшеңдә үзең ахмакланган яки бозыклык кылучы итеп берәү күрсә, начарлык эшли алмаслык җиргә бара.

**Ахирәт көне.** Кыямәт хисабын төштә күрү алты төрле юралына: файдасыз эш; ачлык ирешү; явыз хәл; кайгы; газаплану; хәсрәт.

Әгәр дә төшеңдә Кыямәт хисабы булып, кешеләр туры һәм ялгансыз хисап тотсалар, ике дөньяда да газиз һәм хөрмәтле булырсың.

**Ач (булу).** Төшеңдә ачыкканыңны күрсәң, яисә ачыксаң, бу төшең артык каты яратуың, гашыйк булуың сәбәбеннән керер.

**Ачкыч.** Төштә ачкыч күрү — куәт билгесе, кодрәт ирешер.

Төшеңдә ачкыч югалтсаң, карарыңда азат булырсың.

Катлы-катлы ачкыч булса, яхшы дәүләт һәм карарга ирешүгә юралыныр, барча эшләрең җиңеллек белән барыр.

**Аш, ашау.** Төштә аш күрсәң, ят урыннан сый буларак килсә, дәрәҗә иясе кешеләрдән тәрбия һәм хөрмәт күрерсең.

Әгәр дә төшеңдә ашны ит белән ашасаң, хәрам малдан өлеш чыгарылыр, кулыңа хәрам мал керер.

Әгәр дә татлы ризык ашасаң, яхшыга юралыныр.

Төшеңдә бер өлкән кешенең ашап утырганын күрсәң шул кеше үзенең җаны өчен синнән садака соравы булыр.

podpiska.pochta.ru

**Бу җирлектә Кирмәнчек шәһәрчеге, ханнар зираты, изге чишмәләр барлыгы турында ишеткәч, аны барып күрү, ул хакта нинди дә булса мәгълүмат алу теләге күптән бар иде. Кызыксыну теләге быел яз Мамадыштан Казанга кайтышлый Урта Кирмән авылына алып керде.**




# «Ханнар зираты» сере

Әлеге авылның янәшәсендә генә X–XIV гасырларга караган Кирмән шәһәрчеге бар. Тау башында аның бурадан эшләнгән диварлары олы юлдан ук күренеп тора. Турист ролендә генә булып, чишмә суларын авыз итеп китү – бер хәл, ләкин максат башка иде. Шушы җирлекнең тарихы, ханнар зираты турында мәгълүмат алу өчен тарих укытучысы Ринат абый Хәйруллинны эзләп табарга туры килде. Кызыксынып килеп-китеп йөрүчеләр бер мин генә булмагангадыр инде, Ринат абый һич авырсынмыйча, вак таш түшәгән кул арбасын ишегалдына кертеп куйды да, мине ияртеп тарихи урыннарга алып та китте.

– Төрки-татар дөньясында зиратларны халык яшәгән җирдән су аерып торган. Биредә менә яшәү урыны Кирмәнчек шәһәрчеге булган (тау башында), ә тау астында елга ага. Зират исә елганың бу ягында. Игътибар итсәгез, ул күп җирдә шулай – авылны зираттан инеш аерып тора, - дип сөйләп китте Ринат абый. Бер дә юкка гына болай эшләнмәгән, начар рухлар елга аркылы чыга алмыйлар икән. Ул заманнарда суга табыну көчле булган.

Ә менә ни өчен «Ханнар зираты» дип атала соң ул? Бу җирлек Болгар белән Казаннан шактый ерак. Ханнарны шунда хәтле алып килеп җирләмәгәннәрдер. Ринат абый әйтүенчә, безнең халык бераз арттырырга ярата. «Биредә ханнар булмагандыр инде, ул халык телендә генә шулай атала. Ә фән телендә ул «Беренче Кирмән каберлеге» дип йөртелә. Беренчесе булгач, аның икенчесе дә була инде, икенче каберлек – авылга якынрак, хәзерге фермалар янындагы агачлыкта. Элек анда кыйблага каратып салынган кабер урыннары күренә иде. Хәзер агачлар утырттылар. Ул зиратта ташлар юк, гади халык аны куйдыра алмаган, шуңа күрә ташлар беренче каберлектә генә бар. Беренчесендә – өске катлам, икенчесендә гади халык җирләнгән, - ди Ринат абый. – Кирмәнчек ул – мәйданы 8 гектардан артмаган зур булмаган кенәзлек, ныгытма, ә цитадель өлеше – 2 гектар чамасы».



Элек бу тирәдә һәлакәтләр күп булганга, «Ханнар зираты» яны «Үлем үзәне» дип йөртелгән. Яңа юл әле 5-6 ел элек кенә ачылган, искесе дә шул килеш тора, Урта Кирмәнгә шуннан керәсе. Зиратның төньяк өлеше җимерелеп, җитмешенче елларда Чаллы – Казан юлын салганда, аның балчыгын шунда түрттергәннәр. Кеше үлемнәре белән бәйле һәлакәтләрнең күп булуын юлның зират өстенә әләгүе белән аңлаталар. Борынгы заманда бу тирәдә булган берничә кечкенә авылчык (тимерчеләр, чүлмәкчеләрнең остаханәләре) шул юл астында кала.




«Ханнар зираты»нда казу эшләре беркайчан да башкарылмаган. XIV гасырга караган уннан артык кабер ташы әле бүгенгәчә сакланып калган. Ринат абый Хәйруллин әйтүенчә, элегрәк 28 кабер ташы булган. Төрле зурлыктагы әлеге ташларда язулар кайберсендә тулысынча, икенчеләрендә өлешчә генә сакланган, гасырлар дәвамында табигать тә үз өлешен шактый гына керткән. Халык кайбер каберләргә чардуганнар китереп куя икән – кайберәүләр моны ниндидер нәзер әйтеп, яки теләк теләп эшли. Биредә хәзер кайда кабер булганлыгын чамалау авыр инде, карт агачлар төбе саен кабер дип тәгаенлиләр. Ә менә элек зиратның һәр ягында булган тирән канау урынын бүген дә табарга була әле. Зиратларның чикләре шулай канау казып аерып куелган булган. Бу җирлек турында бик күп кызыклы нәрсәләр язарга була. Бирегә 14 гасырда ушкуйниклар килеп чыгып, аларның Кирмәнчек шәһәрчеген туздырулары турында мәгълүм. Бу хакта елъязмаларда 1395 нче елда телгә алына. Аңа хәтле ничәмә яуларны кичереп, яңадан аякка баса әле ул. Соңгы яудан соң биредәге халык әллә кайларга китмәгән инде, шунда урман эчләренә таралып, авылларга нигез сала. Урта Кирмән авылы элек Хан-Кирмән, аннан соң Татар Кирмәне, Урыс Кирмәне дә пәйда булгач, Урта Кирмән дип атала башлый. Төньяк сугышы чорында (18 гасырда) әсиргә эләккән шведларны бу яклардагы таулардан бакыр чыгару эшләренә китерәләр. Урыс Кирмәне шул чорда нигезләнә.

Бу баруда Кирмәнчек шәһәрчегенә менеп җитә алмадык әле без, зираттан чыкканда кояш баю ягына авышкан, ә минем Казанга таба 140 чакрымлап «әлдерәсе» бар иде. Кабат бармыйча булмый инде.

**Фәнис МОТЫЙГУЛЛИН.**